**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара торган хуҗалык субъектларына карата 2025 елда патентлар нигезендә икътисадый эшчәнлекнең аерым төрләре буенча хезмәт эшчәнлеге алып бара торган чит ил гражданнарын җәлеп итүгә тыю кертү турында

«Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» 2002 елның 25 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законның $18^1$ статьясы 6 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъекты территориясендә эшчәнлек алып бара торган хуҗалык субъектларының үзләре файдалана торган чит ил хезмәткәрләре санын Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) тарафыннан расланган әлеге хуҗалык субъектларына карата патентлар нигезендә икътисадый эшчәнлекнең аерым төрләре буенча хезмәт эшчәнлеге алып бара торган чит ил гражданнарын җәлеп итүгә кертелгән тыюга туры китерү вакытын билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2015 елның 7 декабрендәге 1327 номерлы карары нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара торган хуҗалык субъектларына 2025 елның 31 декабренә кадәр, бу көнне кертеп, патентлар нигезендә Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторында (алга таба – ИЭТГК) күрсәтелгән түбәндәге икътисадый эшчәнлек төрләре буенча хезмәт эшчәнлеге алып бара торган чит ил гражданнарын җәлеп итү тыела:

куркынычлы йөкләрне ташу (ИЭТГК буенча коды 49.20.1);

җиңел автомобильләрдә такси хезмәте күрсәтү һәм автомобиль йөртүчеләре белән бергә җиңел автомобильләрне арендага бирү эшчәнлеге (ИЭТГК буенча коды 49.32);

иминиятләштерү һәм пенсия тәэминаты хезмәтләреннән тыш, финанс хезмәте күрсәтү эшчәнлеге (ИЭТГК буенча коды 64);

мәҗбүри социаль тәэминаттан тыш, иминиятләштерү, яңадан иминиятләштерү, дәүләтнеке булмаган пенсия фондлары эшчәнлеге (ИЭТГК буенча коды 65);

финанс хезмәтләре һәм иминиятләштерү өлкәсендә ярдәмче эшчәнлек (ИЭТГК буенча коды 66);

хокук һәм бухгалтерлык исәбе өлкәсендә эшчәнлек (ИЭТГК буенча коды 69);

ветеринария эшчәнлеге (ИЭТГК буенча коды 75);

сак хезмәтләре, шул исәптән хосусый сак хезмәтләре (ИЭТГК буенча коды 80.10);

отышлы уеннар оештыру һәм уздыру, бәхәскә нигезләнгән килешүләр төзү, лотереяләр оештыру һәм уздыру эшчәнлеге (ИЭТГК буенча коды 92);

компьютерларны, шәхси кулланылыштагы һәм хуҗалык-көнкүреш билгеләнешендәге предметларны төзекләндерү (ИЭТГК буенча коды 95).

2. Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бара торган хуҗалык субъектларына әлеге Указның 1 пунктында каралган икътисадый эшчәнлекнең һәр төре өчен үзләре файдалана торган чит ил хезмәткәрләре санын әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән тыюга туры китерү вакыты әлеге Указ үз көченә кергән көннән өч ай дип билгеләргә.

3. Әлеге Указ рәсми бастырып чыгарылган көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2025 ел, 29 гыйнвар
№ 57